**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

11.11.2020 № 330

**Татарстан Республикасы рәсми порталына ярдәм итү һәм аны үстерү буенча эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы рәсми порталына ярдәм итү һәм аны үстерү буенча эш төркеме төзү турында» 2011 елның 27 маендагы 228 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 2 ноябрендәге 492 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге 494 номерлы, 2014 елның 18 апрелендәге 288 номерлы, 2015 елның 24 августындагы 492 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы 175 номерлы, 2017 елның 21 августындагы 511 номерлы һәм 2018 елның 18 гыйнварындагы 22 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы рәсми порталына ярдәм итү һәм аны үстерү буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эш төркеме составыннан А.Г. Вәлиуллинны, Э.Ф. Хәйруллинны, Р.А. Шәйхетдиновны чыгарырга;

эш төркеме составына кертергә:

Галимова Лилия Камил кызын – Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте җитәкчесен;

Начвин Илья Сергеевичны – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрының беренче урынбасарын;

Улесов Денис Васильевичны – «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директорын;

Фәйзетдинов Ленар Фәнил улын – Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе башлыгын;

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын, аны эш төркеме җитәкчесе урынбасары итеп расларга;

эш төркеме әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

М.Я. Моратовның – «Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, эш төркеме җитәкчесе урынбасары»

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**